КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 1 апрель г.Казань № 241

Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү
срогын озайту турында

Коронавирус йогышлы авыруы таралу куркынычын минимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түләү чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр чыга торган социаль ярдәм чараларын бирүне 2020 елның 1 октябренә кадәр, аларны алучы булган гражданнарга аларны алу өчен гаризаны кабат тапшырмыйча гына, озайтырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарының 2 пунктында билгеләнгән юлда йөрү өчен айлык акчалата түләүне;

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясында билгеләнгән торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торак өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә айлык акчалата түләү, субсидияләрне;

халык өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалануның билгеләнгән нормативлары чикләрендә коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә, ә үзәктән җылылыгы булмаган йортларда яшәүчеләргә – халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм әлеге ягулыкны китерү буенча транспорт хезмәтләре бәясеннән чыгып, субсидияләрне, абонентка даими файдалануга бирелгән фиксацияләнгән телефон элемтәсе челтәренең абонентлар линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидияләрне;

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 7 пунктында билгеләнгән 16 яшькә кадәрге балага айлык пособиене (гомуми белем бирү оешмасында укучы балага – уку тәмамланганчы, ләкин ул 18 яшькә җиткәнче генә);

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 1 статьясында билгеләнгән амбулатор гемодиализ узу урынына һәм кире яшәү урынына транспортта бару чыгымнарын компенсацияләүне, Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларына дәвалану урынына һәм кире яшәү урынына транспортта бару чыгымнарын компенсацияләүне;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карарының 1 пунктында билгеләнгән 18 яшькә кадәрге, даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләүне.

2. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) башкарма комитетлары карарларында билгеләнгән җан башына уртача керемнәре 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүгә карата шундый ук карарны кабул итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 2020 елның 1 апреленә кадәр, әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен, «Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин